Җенси яктан өлгергәндә туган авырлыкларны ничек җиңәргә?

Яшүсмернең җенси яктан өлгерү вакыты — текә аттракцион кебек, ләкин бу чор еш кына кызык түгел. Сиңа нәрсә ярдәм итә ала? Аста китерелгән комментарийларны укы һәм сорауларга үз җавабыңны яз.

«Җенси яктан өлгерү кызлар өчен әллә ни күңелле түгел... Бу чуалчык хисләр тудыра, һәм барысы да начар кебек тоела!» (Оксана).

1

Сиңа җенси яктан өлгерергә туры килер дигән фикер сине

ШАТЛАНДЫРДЫ, КУРКЫТТЫ я ИКЕСЕ ДӘМЕ?

Җенси яктан өлгерүдә иң авыры нәрсә булды?

«Әле генә бәхетле идем, ә инде менә бер минуттан соң кәефем төште. Бу егетләр өчен яхшымы, юкмы икәнен белмим, әмма минем белән нәкъ шулай булды» (Брайан).

2

Син яшүсмер булып киткәч, кәефең кинәт үзгәрә башладымы? Бу нәрсәдән күренде?

Үз хисләреңне контроль астында тотарга сиңа нәрсә ярдәм итә ала?

© 2016 Watch Tower Bible and Tract Society of Pennsylvania

3

Җенси яктан өлгерү вакытында тәнеңә карашың ничек үзгәрде?

Синеңчә, тәнеңә карата карашың нинди булырга тиеш?

«Яшүсмер булып киткәч, мин юри бөкрәеп йөрдем һәм зуррак күлмәкләр кидем. Тәнем ни өчен үзгәрә икәнен белсәм дә, мин үземне уңайсыз хис иттем һәм тартынып йөрдем, оялдым» (Дженис).

4

Җенси яктан өлгерү вакытында каршы җенестәге кешеләргә карашың ничек үзгәрде?

Изге Язмаларда болай дип әйтелә: «Фәхешлектән качыгыз!» (1 Көринтлеләргә 6:18) Ни өчен бу киңәш акыллы, һәм син бу киңәшне тотып яшәргә тәвәккәллегеңне ничек нык ыта аласың?

«Мин хәзер бар малайлар да юньсез һәм йөдәткеч дип уйламыйм. Кайберләре миңа ошый башлады, берәрсенә гашыйк булу инде башка сыймаслык түгел иде. Без кем кемгә ошый дип гел сөйләшеп кенә тора идек» (Алексис).

© 2016 Watch Tower Bible and Tract Society of Pennsylvania

«Мин үз хисләремне күрсәтми идем. Үз вакытында әти-әниемә хисләремне күбрәк ачкан булсам иде! Шул чак яшүсмер вакыты миңа, бәлки, күбрәк шатлык китерер иде» (Джереми).

5 Яшүсмер буларак, авырлыкларга очраганда, әти-әниең белән (я ышанычлы башка берәр олы кеше белән) сөйләшү уңайсыз булса да, ни өчен сөйләшергә яхшы булыр иде? **(Гыйбрәтле сүзләр 17:17 укы)**

Олы кешеләрнең кайсысына син күбрәк ышанасың һәм йөрәгеңне ача аласың?

6 Әти-әниең сиңа яшүсмер чагындагы үзгәрешләргә дөрес карарга ничек ярдәм итә?

Син әти-әниеңнең үзең өчен тагын нәрсә эшләүләрен теләр идең?

«Җенси яктан өлгергәндә, мин үземне бик уңайсыз хис иттем. Әти-әнием үземә ярдәм итмәгән булса, мин үземне тагы да начаррак хис итәр идем. Әнием мине һәрвакыт үзем белән булачак дип һәм мин аңа теләсә кайсы вакытта мөрәҗәгать итә алам дип ышандырды» (Карина).

© 2016 Watch Tower Bible and Tract Society of Pennsylvania

«Җәнси яктан өлгерү вакыты башланган яшүсмерләргә мин шуны әйтергә телим: башта бу чор сиңа куркыныч кебек күренергә мөмкин, ләкин аны бөтен тормышың белән чагыштырсаң, бу чор бик кыска. Нәкъ бу вакытны син балигъ кеше булып китәсең» (Дейвид).



7 Җәнси яктан өлгерү чорын әле кичерәчәк балаларга син нинди киңәш бирер идең?

Әти-әниеңә сорау бир

Ышанасыңмы, юкмы, әмма әти-әниең дә синдә булган үзгәрешләрне кичергән. Алар җәнси яктан өлгерү вакытларын ничек кичергән? Син моңа кагылышлы нинди ике сорау бирер идең? Бу сорауларны битнең астагы өлешендә язып куй, аны кисеп ал һәм әти-әниеңә күрсәт.

1

2

© 2016 Watch Tower Bible and Tract Society of Pennsylvania